ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 июнь, 2022 ел № 15/6

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьялары, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 92, 93, 94 статьялары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы турында» 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы Карары белән расланган (Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4, 2007 елның 4 июлендәге 23/4, 2007 елның 25 декабрендәге 28/10, 2008 елның 29 февралендәге 30/7, 2009 елның 9 апрелендәге 40/6, 2009 елның 10 сентябрендәге 42/7, 2010 елның 31 мартындагы 47/7, 2010 елның 27 декабрендәге 7/6, 2011 елның 15 декабрендәге 15/7, 2012 елның 5 июлендәге 19/15, 2012 елның 20 декабрендәге 22/19, 2013 елның 29 августындагы 26/17, 2014 елның 21 февралендәге 29/17, 2014 елның 16 октябрендәге 33/17, 2015 елның 27 февралендәге 38/14, 2015 елның 23 июлендәге 41/11, 2016 елның 24 февралендәге 6/10, 2017 елның 22 февралендәге 15/10, 2017 елның 10 августындагы 18/9, 2017 елның 15 декабрендәге 21/16, 2018 елның 27 апрелендәге 24/8, 2018 елның 11 декабрендәге 28/9, 2019 елның 1 августындагы 32/13, 2019 елның 6 декабрендәге 34/14, 2020 елның 17 июнендәге 40/3, 2020 елның 29 декаберендәге 4/7, 2021 елның 27 маендагы 7/6, 2021 елның 3 ноябрендәге 9/5 номерлы Карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) **9 статьяның 1 өлеше 41 пунктында** «, ясалма җир участогы хасил итү турында килешү төзү хокукына ачык аукцион үткәрү» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) **34 статьяның 6 өлешен түбәндәге** редакциядә бәян итәргә:

«6. Шәһәр Хакиме Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты, Россия Федерациясе сенаторы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары депутаты була алмый, Россия Федерациясенең башка дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, шулай ук дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын били алмый, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса.»;

3) **37 статьяның 3.1 өлешен** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1 Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты, Россия Федерациясе сенаторы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнары депутаты була алмый, Россия Федерациясенең башка дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, шулай ук дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын били алмый, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса.»;

4) **41 статьяның 4 өлешендә** түбәндәге эчтәлектәге **30 пункт** өстәргә:

«30) федераль закон нигезендә муниципаль берәмлек ихтыяҗлары өчен ясалма җир участоклары булдыру өчен кирәкле эшләрне башкаруны тәэмин итү;»

2. Әлеге Карар, үз көченә керү гамәлдәге законнар белән башка вакытта каралган аерым нигезләмәләрдән тыш, матбугатта рәсми басылган көннән үз көченә керә.

3. Яр Чаллы шәһәре Хакиме Н.Г. Мәһдиевка әлеге Карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә тапшырырга.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан 2022 елның 1 июлендә теркәлде. Дәүләт теркәве номеры RU 163020002021001